**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге составына керүче Кнәз авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

24 ноябрь, 2025 ел № 1

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Кнәз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Кнәз авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Советының 2019 елның 05 декабрендәге 12/4 номерлы карары нигезендә 2025 елның 21 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл җирлеге Кнәз авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм **I, II** төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кнәз авылында бистә эчендәге юлларны асфальт һәм вак таш белән ремонтлау һәм реконструкцияләү);**

**- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Кнәз авылында суүткәргечне ремонтлау).**

**«ӘЙЕ» «ЮК»**

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы **140** кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – **95** кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы <u>90</u> кеше тавыш бирде;

**«Юк»** позициясе өчен җыенында катнашучы <u>5</u> кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Кнәз авылы гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2026 елда яшәү урыны буенча Кнәз авыл Кнәз авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм **I, II** төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яштәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

**- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Кнәз авылында бистә эчендәге юлларны асфальт һәм вак таш белән ремонтлау һәм реконструкцияләү);**

**- проектлаштыру, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итә торган су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын төзү һәм ремонтлау (Кнәз авылында сууткәргечне ремонтлау).**

3. РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын Князево авыл җирлеге территориясендә теркәлгән взнослардан азат итәргә.

4. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Кнәз авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

5. Тукай муниципаль районы Кнәз авыл җирлеге Кнәз авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Кнәз авыл җирлеге башлыгы И.М.Вилданов

Совет КНЯЗЕВСКОГО сельского поселения
ОГРН 1021601374167
р 05-11786/09
ИНН 1639009721